**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**28.06.2022 ел** **№ 637**

# Балигъ булмаган зат ия булган күчемсез милекне читләштерү буенча алыш-бирешләр кылуга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2009 елның 09 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Биектау муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кушымтада бирелгән Балигъ булмаган зат ия булган күчемсез милекне читләштерү буенча алыш-бирешләр кылуга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын расларга.

2. Биектау муниципаль районы башкарма комитетының Опека һәм попечительлек секторына расланган административ регламент нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашырырга.

3. Үз көчен югалткан дип танырга:

3.1. 1.19 пункт. «Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2016 елның 06 маендагы 747 номерлы карарының Балигъ булмаган зат ия булган күчемсез милекне читләштерү буенча алыш-бирешләр кылуга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентның 19 нчы кушымтасын.

3.2. 1.19 пункт. Биектау муниципаль районы башкарма комитетының «Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2016 елның 06 маендагы 747 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 2 мартындагы 539 номерлы

карары,19 нчы кушымтасын.

3. Әлеге карар Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталының рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарылырга һәм урнаштырылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Сабирҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф.Хисамутдинов

Кушымта
«Расланды»
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 28.06. 637нче номерлы карары белән

**Балигъ булмаган зат ия булган күчемсез милекне читләштерү буенча алыш-бирешләр кылуга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең АДМИНИСТРАТИВ РЕГЛАМЕНТЫ**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент балигъ булмаган зат ия булган күчемсез милекне читләштерү буенча алыш-бирешләр кылуга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Хезмәт алучылар: балигъ булмаган зат ия булган күчемсез милекне читләштерү буенча алыш-бирешләр кылуга алдан рөхсәт алырга теләүче Россия Федерациясенең ундүрт яшькә җиткән балигъ булмаган гражданнары, ундүрт яшькә җитмәгән балигъ булмаган гражданнарның законлы вәкилләре (алга таба - мөрәҗәгать итүчеләр).

1.3. Дәүләт хезмәте гариза бирүченең яшәү урыны буенча «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУның (алга таба - хезмәт) опека һәм попечительлек секторы тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Опека һәм попечительлек секторының урнашкан урыны: ТР, Биектау т/юл ст. п., Мәктәп ур., 17й, 5 каб.

Опека һәм попечительлек секторының кабул итү графигы: дүшәмбе 8.00 дән 12.00 гә кадәр, сишәмбе 13.00 дән 16.00 гә кадәр, шимбә, якшәмбе - ял көннәре, төшке аш 12.00 дән 13.00 гә кадәр.

Керү шәхесне таныклаучы документлар буенча.

1.3.2. Белешмә телефоны: (843)6523269

1.3.3. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУның рәсми сайтының адресы: (http:// www.//vysokaya-gora.tatarstan.ru).

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУ биналарында урнашкан дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

2) «Интернет» челтәре аша:

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының рәсми сайтында (http://www.vysokaya-gora.tatarstan.ru).

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) хезмәткә телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яисә телефон аша);

4) опека һәм попечительлек органына язмача мөрәҗәгать (шул исәптән электрон документ рәвешендә) иткәндә.

1.3.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы (шәһәр округы) мәгариф бүлегенең муниципаль психолог-педагогик хезмәте бинасында урнашкан дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен дәүләт хезмәте турында мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

2) «Интернет» челтәре аша муниципаль районның рәсми сайтында (http://www.vysokaya-gora.tatarstan.ru)/;

3) Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

4) Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

5) Башкарма комитетта;

Телдән мөрәҗәгать иткәндә - шәхсән яисә телефоннан;

Язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ рәвешендә) - кәгазьдә почта аша, электрон рәвештә электрон почта аша.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге норматив актлар нигезендә башкарыла:

1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Гражданнар кодексы (алга таба - РФ ГК) ("РФ законнар җыентыгы", 05.12.1994, №32, 3301 ст., "Россия газетасы", 238-239, 08.12.1994);

1995 елның 29 декабрендәге 223-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Гаилә кодексы (алга таба – РФ Гаилә кодексы) ("РФ законнары җыентыгы", 01.01.1996, №1, 16, "Россия газетасы", № 17, 27.01.1996);

"Опека һәм попечительлек турында" 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 48-ФЗ номерлы Федераль закон) ("Россия газетасы" 2008 елның 30 апрелендәге 94 номерлы, 2008 елның 7 маендагы 31-32 номерлы "Парламент газетасы", 2008 елның 28 апрелендәге "РФ законнары җыентыгы"1755 ст.);

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) («Российская газета», №168, 30.07.2010, Россия Федерациясе законнары Җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст.);

2009 елның 13 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Гаилә кодексы ("Республика Татарстан" 2009 елның 16 гыйнварындагы 8 номерлы, "Ватаным Татарстан" 2009 елның 17 гыйнварындагы № 8, Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, N 1, 2009 елның гыйнвары);

«Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба - 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы)

(Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, N 2, 2004 елның феврале, «Республика Татарстан» 2004 елның 2 мартындагы N 43-44, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре җыентыгы һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары N 21, 26 май, 2004 ел);

“Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (“Ватаным Татарстан” 2008 елның 22 мартындагы №54, “Татарстан Республикасы” 2008 елның 25 мартындагы №60-61, Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, N 3, март 2008 ел);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында" 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары (алга таба - 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре җыентыгы һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010, № 46, 2144 ст. 20.12.2011, №48, 2612 ст. 25.05.2012, №40, 1252 ст.);

Биектау муниципаль районы Советының 2015 елның 21 сентябрендәге 7 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставы (алга таба – Устав);

Биектау муниципаль районы Советының 2017 елның 16 февралендәге 122 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУсе турындагы Нигезләмә (алга таба – БК турында Нигезләмә);

Биектау районы Советының 2010 елның 22 декабрендәге 27 номерлы карары белән расланган Биектау муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы турындагы нигезләмә (алга таба - Бүлек турындагы нигезләмә);

Биектау муниципаль районы башкарма комитетының "Эчке тәртип кагыйдәләрен раслау турында" карары белән 30.12.2010 № 3338 (алга таба эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре).

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

- техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документларга кертелгән мәгълүматлар (муниципаль хезмәт нәтиҗәсе) документтагы мәгълүмат нигезендә кертелгән мәгълүматларга туры килмәүгә китергән хата (ялгыш язу, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яки шуның ише хата);

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны – «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә муниципаль районның шәһәр (авыл) җирлегендә яки Татарстан Республикасы шәһәр округында булдырылган дәүләт һәм

муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза астында (алга таба - гариза) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 1 пунктында (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон) каралган сорату аңлашыла.

Гаризаның формасы әлеге Регламентка 1 нче кушымтада китерелгән.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләпнең исеме | Стандарт таләбенең эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәт күрсәтүенең исеме | Балигъ булмаган зат ия булган күчемсез милекне читләштерү буенча алыш-бирешләр кылуга алдан рөхсәт бирү | 24.04.2008 48-ФЗ Федераль законның 21ст.;<br>30.11.1994 РФ ГаиләК 28 ст. (беренче өл.)<br>30.11.1994 РФ ГаиләК 37 ст. (беренче өл.)<br>12.01.2013 8-ТРЗ ТР Законы |
| 2.2. Хезмәт күрсәтүче орган исеме | Гариза бирүченең яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы (шәһәр округы) Башкарма комитеты | 12.01.2013 8-ТРЗ ТР Законы |
| 2.3. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Балигъ булмаган зат ия булган күчемсез милекне читләштерү буенча алыш-бирешләрне гамәлгә ашыруга күрсәтмә (карар) рәвешендә рөхсәт<br>Дәүләт хезмәтен хат рәвешендә күрсәтүдән баш тарту | 24.04.2008 48-ФЗ Федераль законның 21ст.;<br>12.01.2013 8-ТРЗ ТР Законы |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы | Гражданнарның дәүләт хезмәтен күрсәтүгә кагылышлы язма мөрәҗәгатьләрен карау аларны теркәгән көннән алып 15 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла. | 24.04.2008 48-ФЗ Федераль законның 21ст.; |
| 2.5. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле дәүләт хезмәтен күрсәтү | 1. Ата-аналарның (икесенең дә) яисә аларны алмаштыручы затларның килешүне башкаруны рөхсәт итү турындагы үтенече белән гаризасы | |

| | | |
|---|---|---|
| өчен закон яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның, шулай ук дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрнең тулы исемлеге | (мөрәҗәгать итүче), яисә законлы вәкилләрнең язма ризалыгы белән эш итүче 14ундүрт яшькә җиткән балигъ булмаган затның гаризасы (1нче кушымта);<br>2. Ата-аналарның яисә аларны алмаштыручы затларның паспортларының оригиналы һәм күчермәләре;<br>3. Балигъ булмаган баланың туу турында таныклыгының оригиналы һәм күчермәсе (14 яшьтән паспорты);<br>4. Ата-ана һәм яңа сатып алына торган күчемсез мөлкәткә техник паспортларның күчермәләре;<br>5. Җир кишәрлегенә хокук билгели торган документлар;<br>6. Торак сатып алынган очракта ана капиталы акчалары җәлеп ителгән очракта:<br>- ана капиталына сертификат күчермәсе;<br>- ана капиталын индексацияләү турында белешмә.<br>Дәүләт хезмәтен алу өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче опека органына шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазь чыганакларда түбәндәге ысулларның берсе тарафыннан тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин: | |

| | | |
|---|---|---|
| | шәхсән (мөрәҗәгать итүче исеменнән ышанычнамә нигезендә эш итүче зат тарафыннан);<br>почта аша.<br>Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең Бердәм порталы аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында белгеч тарафыннан соралырга мөмкин булган документлар:<br>- аның килешү төзергә рөхсәт бирелгән муниципаль районныкы булуын раслый торган балигъ булмаганны теркәү урыны буенча йорт кенәгәсеннән өземтә;<br>- торак мәйданының шәхси финанс счетлары һәм йорт кенәгәсеннән торак урыннарны сатып алу (алмаштыру) урыныннан аерым алынган өземтәләр;<br>- күчемсез мөлкәткә хокук билгели торган документлар, сату урыныннан һәм сатып алу (алмашу) урыныннан аерым (Росреестр, БТИ). | |
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда аларны килештерү дәүләт хезмәте күрсәтү өчен таләп ителә торган һәм | Дәүләт хезмәтен күрсәтүне килештерү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | | |
| 2.8. Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1. Бирелгән документларның 2.5 п. күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве.<br>2. Бирелә торган документларда алдан килештерелмәгән төзәтмәләр.<br>3. Фактта яшәү урыны буенча булмаган мөрәҗәгать. | |
| 2.9. Хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Баш тарту өчен нигезләр:<br>1. Законлы вәкилләрнең ризалыгы булмау<br>2. мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтү хокукы шулар нигезендә билгеләнә торган тиешенчә рәсмиләштерелмәгән документларны, тулы булмаган һәм (яисә) дөрес булмаган белешмәләрне тапшыру.<br>3. Балигъ булмаган баланың мөлкәти хокукларын кысу<br>Дәүләт хезмәтен туктатып тору өчен нигезләр юк. | 12.01.2013 8-ТРЗ ТР Законы |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасын яисә башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм алу нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.11. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен түләүне алу тәртибе, күләме һәм алу нигезләре, мондый түләүнең күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында сорату биргәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь срогы | Мөрәҗәгать итүчене кабул итүне (хезмәт күрсәтүне) көтүнең максималь срогы 15 минуттан артмаска тиеш. Дәүләт хезмәтен алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән | 27.07.2010 210-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза бирүченең соратуын теркәү срогы һәм тәртибе | Гариза кергән көндә.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә кергән сорату ял көненнән (бәйрәмнән) соң беренче эш көнендә теркәлә. | 27.07.2010 210-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы һәм янгын сүндерү системалары, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһаз, мәгълүмат стендлары булган биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидларның дәүләт хезмәтен күрсәтү урынына каршылыксыз керүе тәэмин ителә (бинага уңайлы керү-чыгу һәм аның эчендә хәрәкәт итү).<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматлары мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла | вазыйфаи регламентлар, вазыйфаи инструкцияләр |

| | | |
|---|---|---|
| 2.15. Дәүләт хезмәтеннән файдалану мөмкинлеге һәм аның сыйфаты күрсәткечләре | Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре:<br>- бинаның җәмәгать транспорты йөри торган урында урнашуы;<br>- кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган биналар булу;<br>- мәгълүмати стендларда, Интернет челтәрендә Башкарма комитетның мәгълүмат ресурсларында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләренең Бердәм порталында дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>- мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан документлар кабул иткәндә һәм тапшырганда чиратлар;<br>- дәүләт хезмәтен күрсәтү срокларын бозу;<br>- дәүләт хезмәтен күрсәтүче хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять;<br>- дәүләт хезмәтен күрсәтүче хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында сорату биргәндә һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен алганда дәүләт хезмәтен күрсәтүче вазыйфаи затның да, мөрәҗәгать итүченең дә бер тапкыр үзара хезмәттәшлеге күздә тотыла. Хезмәттәшлек | 27.07.2010 210-ФЗ номерлы Федераль закон |

| | | |
|---|---|---|
| | дәвамлылыгы регламент белән билгеләнә.<br>Дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (алга таба – КФҮ) дәүләт хезмәтен күрсәткәндә, КФҮнең ерак эш урыннарында консультация, документларны кабул итү һәм бирү белән КФҮ белгече шөгыльләнә.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан Биектау муниципаль районы сайтында, дәүләт хезмәтләрен (функцияләрен) күрсәтүнең Бердәм порталында, КФҮ дә алынырга мөмкин. | |
| 2.16. Электрон рәвештә дәүләт хезмәтен күрсәтү үзенчәлекләре | Консультация Интернет-кабул итү бүлмәсе аша бирелә.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар граждан тарафыннан шәхсән үзе опека һәм попечительлек органына йә «Бердәм дәүләт хезмәтләре порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын, региональ дәүләт хезмәтләре порталы (адресы: http://www.vysokaya-gora.tatarstan.ru) яисә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә опека һәм попечительлек органының рәсми сайтын кулланып, яисә опека һәм попечительлек органында үзара хезмәттәшлек турында килешүләр төзелгән күпфункцияле дәүләт хезмәтләре күрсәтү үзәкләренең вазыйфаи затлары аша, аннары рөхсәт алганда документларның төп нөсхәләрен күрсәтеп | 27.07.2010 210-ФЗ номерлы Федераль закон |

| | | |
|---|---|---|
| | бирелергә мөмкин.<br>Опека һәм попечительлек органына шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта гражданин гариза биргәндә паспортын яисә аның шәхесен раслаучы башка документны күрсәтергә тиеш. | |

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау

3.1.1. Балигъ булмаган затныкы булган күчемсез мөлкәтне читләштерү буенча алыш-бирешләр үткәрүгә алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү;

2) мөрәҗәгать итүчене кабул итү, документлар кабул итү (әлеге регламентның 2.5 п. кара);

3) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратулар формалаштыру һәм җибәрү;

4) балигъ булмаган затның күчемсез мөлкәтен читләштерү буенча алыш-бирешләр үткәрүгә алдан рөхсәт бирү буенча рөхсәт әзерләү;

5) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү;

6) нигез булганда, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында хат юллау.

3.1.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча эшчәнлекнең эзлеклелеге блок-схемасы 2 нче кушымтада китерелгән.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү.

Мөрәҗәгать итүче шәхсән, телефон, электрон почта аша (адресы:_Guzeliya.Valieva@tatar.ru һәм (яисә) хат дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен опека һәм попечительлек секторына мөрәҗәгать итә.

Опека һәм попечительлек секторы белгече мөрәҗәгать итүчене, шул исәптән дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультацияли.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: консультацияләр, дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле документлар исемлегенең составы, формасы һәм эчтәлеге буенча кисәтүләр.

3.3. Мөрәҗәгать итүчене кабул итү, документлар кабул итү.

3.3.1. Гариза бирүче әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны шәхсән үзе хезмәткә тапшыра.

3.3.2. Кабул итүне алып баручы сектор белгече түбәндәгеләрне башкара:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгеләү;

документларның булуын тикшерү;

тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү (документларның күчермәләрен тиешенчә рәсмиләштерү, документларда ассызыклаулар, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм килештерелмәгән башка төзәтүләр булмау).

Әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаганда, опека һәм попечительлек секторы белгече мөрәҗәгать итүчегә бәяләмә бирү өчен гариза кабул итү датасы һәм аңа теркәлә

торган документларны кабул итү турында хәбәр итә, шуннан соң әлеге Регламентның 3.3.3. пунктчасында каралган процедуралар гамәлгә ашырыла.

Әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, мөрәҗәгать итүче гаризаны биргәндә хезмәт белгече гаризаны теркәү өчен каршылыклар барлыгы турында шәхсән аңа хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, документларны аңа кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән документлар, гаризаларны теркәү журналында теркәү язуы, расписка яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Опека һәм попечительлек секторы белгече әлеге Регламентның 2.9 пунктында каралган дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Хезмәтләр күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, опека һәм попечительлек органы белгече баш тарту турында хат әзерли һәм мөрәҗәгать итүчегә аңа кул куйган датадан 3 көн эчендә җиткерә. Бер үк вакытта мөрәҗәгать итүчегә барлык документлар кире кайтарыла һәм карарга шикаять белдерү тәртибе аңлатыла. Әлеге Регламентның 3.7 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, белгеч мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән документлардагы белешмәләрне тикшерү эшен оештыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза теркәлгән көннән алып ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: документларны тикшерү һәм рөхсәтне әзерләү яисә кире кагу турында карар кабул итү.

3.4. Ведомствоара соратулар формалаштыру һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү.

3.4.1. Опека һәм попечительлек секторы белгече электрон рәвештә ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә соратулар җибәрә:

- балигъ булмаган баланы теркәү урыны буенча йорт китабыннан килешүгә рөхсәт бирелә торган муниципаль районга керүне раслый торган өземтәгә.

- финанс шәхси счетларына һәм торак биналарны сату һәм сатып алу (алмаштыру) урыныннан торак мәйданыннан аерым йорт китабыннан аерым өземтәләргә.

- күчемсез мөлкәткә хокук билгели торган документларга, сату урыныннан һәм сатып алу (алмашу) урыныннан аерым (Росреестр, БТИ).

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.3.3. пунктчасында каралган процедура тәмамланган вакыттан алып бер эш көне эчендә.

Процедуралар нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында җибәрелгән соратулар.

3.4.2. Опека һәм попечительлек секторы соратулары буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнар тарафыннан автоматлаштырылган режимда гамәлгә ашырыла:

- соратуны эшкәртү һәм соратыла торган мәгълүматларны эзләү,

- соратыла торган белешмәләрнең ведомствоара электрон хезмәттәшлеге ярдәмендә йә, соратып алына торган белешмәләр булмаган очракта, соратып алынучы белешмәләрне бирүдән баш тарту турында, баш тартуның сәбәпләрен күрсәтеп, хәбәрнамә җибәрү.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар опека һәм попечительлек секторының соратулары кергән вакыттан алып биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: соратуга җавап яки әлеге Регламентның 3.4 п. күрсәтелгән белешмәләрне бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә.

3.5. Балигъ булмаган затның күчемсез мөлкәтен читләштерүгә килешүне гамәлгә ашыруга алдан рөхсәт бирү турында күрсәтмә (карар) яисә кире кагу турында хат әзерләү.

3.5.1. Опека һәм попечительлек секторы белгече тәкъдим ителгән документлар нигезендә балигъ булмаган затныкы булган күчемсез мөлкәтне читләштерү буенча алыш-бирешләрне гамәлгә ашыруга алдан рөхсәт бирү турында күрсәтмә (карар) проектын әзерли һәм аны килештерүгә җибәрә (кирәк булган очракта катлаулы мәсьәләләр балигъ булмаганнарның хокукларын яклау комиссиясендә карала, бу тәкъдим характерында) һәм опека һәм попечительлек органы җитәкчесендә раслый яки тиешле карар белән баш тарту турында хат әзерли.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң биш эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: 3.7 п. нигезендә әзерләнгән балигъ булмаган затның күчемсез милеген читләштерү буенча алыш-бирешне башкаруга алдан рөхсәт бирү турында күрсәтмә (карар)

3.6. Мөрәҗәгать итүчегә хезмәт нәтиҗәсен бирү.

3.6.1. Опека һәм попечительлек секторы белгече, балигъ булмаган затның күчемсез мөлкәтен читләштерү буенча килешүне гамәлгә ашыруга алдан рөхсәт бирү турында имзаланган күрсәтмәне (карарны) алып, аны терки һәм мөрәҗәгать итүчегә тапшыра (җибәрә). Тискәре нәтиҗә булган очракта, шәхсән үзенең кулына баш тарту турында хат тапшыра яисә, 3.7 п. нигезендә почта аша хәбәр итеп,

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар процедура тәмамланганнан соң 3.5.1 пунктчасында каралган вакыттан бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү (җибәрү).

3.7. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында хат җибәрү.

3.7.1. Опека һәм попечительлек секторы белгече рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проектын (алга таба - баш тарту турында хат) әзерли.

Әзерләнгән баш тарту турында хат проекты Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) опека секторы җитәкчесенә имзага җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар баш тарту өчен нигезләр ачыкланганнан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: имза салуга юнәлдерелгән баш тарту турында хат проекты.

3.7.2. Опека һәм попечительлек секторы җитәкчесе баш тарту турында хат

проектын имзалый һәм опека һәм попечительлек секторы белгеченә кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар бер көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: кул куелган баш тарту турында хат.

3.7.3. Опека һәм попечительлек секторы белгече мөрәҗәгать итүчегә аңа кул куйган көннән алып 3 көн эчендә баш тарту турында хат җиткерә. Бер үк вакытта мөрәҗәгать итүчегә барлык документлар кире кайтарыла һәм карарга шикаять белдерү тәртибе аңлатыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура процедура 3.7.2 пунктчасында каралган процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү.

3.8. Техник хатаны (язу, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хата) төзәтү (3 нче кушымта).

3.9 Дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең күпфункцияле үзәге, КФҮнең читтән торып эш урыны аша дәүләт хезмәтен күрсәтү (4 нче кушымта).

## 4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерү, дәүләт хезмәтен күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерү, җирле үзидарә органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләрне карау, карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып тора:

- муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;
- билгеләнгән тәртиптә башкарыла торган эш кәгазьләрен алып баруны тикшерү;
- дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларының үтәлешенә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерү үткәрү.

Контроль тикшерүләр план нигезендә һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырганда дәүләт хезмәте күрсәтү (комплексы тикшерүләр) белән бәйле барлык мәсьәләләр дә карала ала, яисә гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча.

Дәүләт хезмәт күрсәткәндә һәм карар кабул иткәндә гамәлләрнең башкарылуын тикшереп тору өчен сектор җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр бирелә.

4.2. Дәүләт хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешенә агымдагы контроль дәүләт хезмәте күрсәтү эшен оештыруга җаваплы белгеч, эш кәгазьләре хезмәте белгечләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге опека һәм попечительлек секторының структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи регламентлар турындагы нигезләмәләр белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җаваплы башкаручы мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгатьләрен вакытында тикшермәгән өчен җаваплы була.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, муниципаль хезмәтне күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның яисә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының йә дәүләт яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, шулай ук дәүләт хезмәтләрен күрсәтү функцияләрен гамәлгә ашыручы оешмаларның яки аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) гариза бирүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү предметы

5.1. Дәүләт хезмәтен алучылар дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы опека һәм попечительлек секторы хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмавына) Татарстан Республикасы муниципаль районы башкарма комитетына судка кадәр шикаять белдерү хокукына ия.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында соратуны теркәү вакытын, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында күрсәтелгән соратуны бозу;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогын бозу. Әгәр шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт хезмәтләре күрсәтү функциясе тулы күләмдә йөкләнгән булса, күрсәтелгән очракта күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) мөрәҗәгать итүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү мөмкин;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган документларны яисә мәгълүматны яисә гамәлләр башкаруны таләп итү;

4) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән баш тарту нигезләре каралмаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту. Әгәр шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә «Дәүләт

һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт хезмәтләре күрсәтү функциясе тулы күләмдә йөкләнгән булса, күрсәтелгән очракта күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) мөрәҗәгать итүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү мөмкин;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган түләүне таләп итү;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның яисә дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмаларның яисә аларның хезмәткәренең дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтмәләрнең билгеләнгән вакытын бозуы. Әгәр шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт хезмәтләре күрсәтү функциясе тулы күләмдә йөкләнгән булса, күрсәтелгән очракта күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) мөрәҗәгать итүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү мөмкин;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогын яки тәртибен бозу;

9) федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән туктатып тору нигезләре каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору. Әгәр шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт хезмәтләре күрсәтү функциясе тулы күләмдә йөкләнгән булса, күрсәтелгән очракта күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) мөрәҗәгать итүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү мөмкин;

5.2. Шикаять язмача кәгазьдә яки электрон формада тапшырыла.

Шикаятьне почта аша, күпфункцияле үзәк аша, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Биектау муниципаль районының рәсми сайтыннан (http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/) һәм Татарстан Республикасының Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) файдаланып, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итәргә мөмкин.

5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең оештыручысына, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру

турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларга яисә югары органга (ул булган очракта) кергән шикаять аны теркәгәннән соң унбиш эш көне эчендә каралырга тиеш, ә дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәкнең оештыручысының, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның мөрәҗәгать итүченең документларын кабул итүдән яисә җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакытын бозуга карата шикаять белдергән очракта - аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.4. Шикаять түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яисә) хезмәткәренең, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, аларның җитәкчесенең һәм (яисә) хезмәткәрләренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүмат яисә мөрәҗәгать итүче – юридик затның атамасы, урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазифаи затының, яки муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмаларның яисә аларның хезмәткәренең шикаять ителүче карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазифаи затының, яки муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмаларның яисә аларның хезмәткәренең карары һәм гамәле (гамәл кылмавы) белән килешмәвенә нигез булган дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аның дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яисә аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.5. Шикаятьтә тасвирланган хәлләрне раслаучы документларның күчермәләре шикаятькә кушымта итеп бирелергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа кушып бирелә торган документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаять аны тапшырган муниципаль хезмәт алучы тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаятьне канәгатьләндерү, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда

җибәрелгән хаталар һәм ялгышларны төзәтү, гариза бирүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган акчаларны кире кайтару формасында;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.7 пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннең икенче көненнән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язма рәвештә һәм гариза бирүче теләге буенча электрон формада шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилле җавап җибәрелә.

5.8. Шикаятьне карап тикшерү барышында яисә карап тикшерү нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы билгеләре яки җинаять билгеләре ачыкланганда, шикаятьне карап тикшерү буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 11.2 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән нигезләрдә кичекмәстән прокуратура органнарына юллый.

**Балигъ булмаган зат ия булган күчемсез милекне читләштерү буенча алыш-бирешләр кылуга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта**

Руководителю исполнительного комитета
Высокогорского муниципального района

___________________________________

__________________________________

граждан (-ка)__________________

(Ф.И.А.)

____________________________________,

паспорт______________________________

____________________________________,

түбәндәге адрес буенча яшәүче:________

____________________________________,

телефон: _____________________________

ГАРИЗА

_______________________________________________, адресы буенча урнашкан

______________________________________________________________________________

(хосусыйлаштырылган, милеккә сатып алынган, кооператив, дәүләт) фатирны, (торак йортны)

читләштерергә (сату-алу, алмашу) рөхсәт бирүегезне үтенәм,

_____ кв.м гомуми мәйданлы, _____ кв.м торак мәйданлы, бүлмәләр саны______,

фатир милекчеләре булып тора:

______________________________________________________________________________

**(Ф.И.А., өлешләрне күрсәтергә)**

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

шул исәптән балигъ булмаган балалар (бала):

______________________________________________________________________________

(Ф.И.А.., туган көне, өлешләрне күрсәтергә)

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

____________________________________________________________________белән бәйле

(торак шартларны яхшырту, күченү һәм б.ш.)

__________________________________________________________________ сатып алабыз,

(фатир (җир кишәрлегендә урнашкан торак йорт)

_____ кв.м гомуми мәйданлы, _____ кв.м торак мәйданлы, бүлмәләр саны_______

___________________________________________________адресы буенча урнашкан

_____________________________________________________________________________

балигъ булмаган(нар)га______________________________________________ анда

(Ф.И.А.)

___________ өлеш бүлеп биреләчәк.

Өстәмә мәгълүмат (кредит җәлеп итү, сатып алына торган фатирны залогка бирү һәм башка хокукый чикләүләр, ана (гаилә) капиталына дәүләт сертификатын куллану):

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________.

Балаларның мөлкәти һәм торак хокуклары кысылмый.

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең ТР буенча идарәсендә сату-алу шартнамәсен теркәгәннән соң ике атна эчендә опека һәм попечительлек бүлегенә сату-алу шартнамәсенең һәм хокукларны дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклыкларның күчермәләрен тапшырырга.

Минем шәхси мәгълүматлар белән эшкә рөхсәт бирәм.

____________________ _________________

(дата) (имза)

Мин,______________________________________________________________

(14 яшьтән өлкәнрәк балигъ булмаганның ФИА)


законлы вәкилләр гаризасы белән ризалашам.

________________________ ____________________

(дата) (имза

**Балигъ булмаган зат ия булган күчемсез милекне читләштерү буенча алыш-бирешләр кылуга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта**

## Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге блок-схемасы



**Балигъ булмаган зат ия булган күчемсез милекне читләштерү буенча алыш-бирешләр кылуга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта**

ТР муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә

Техник хатаны төзәтү турында
гариза

Мин, ___________________________________________________________________________

*(фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча күрсәтелә)*

Түбәндәге адрес буенча яшәүче_______________________________________________________

_____________________________________________________________________________

*(гариза бирүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)*

_____________________________________________________________________________

*(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаган документ исеме, аның сериясе, номеры, бирелү датасы)*

_____________________________________________________________________________

*(документ биргән органның исеме)*

Балигъ булмаган зат ия булган күчемсез мөлкәтне читләштерү буенча алыш-бирешләр кылуга алдан рөхсәт бирү буенча карарда җибәрелгән техник хатаны төзәтүне сорыйм _____________________________________________

________ №__________
карар датасы карар номеры

Техник хатаны төзәтү турында мәгълүмат алуга риза

Дата: Имза:

**Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешенә контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Сектор мөдире<br>Г. А. Вәлиева | (8-84365) 2-32-69 | guzeliya/valieva@tatar.ru |
| Әйдәп баручы белгеч<br>С.С. Титова | (8-84365) 2-32-69 | S.Titova@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе Хисамутдинов Равил Фәрит улы | 2-30-61 | biektau@tatar.ru |
| Социаль мәсьәләләр буенча җитәкче урынбасары Сабирҗанов Ринат Рәшит улы | 2-30-87 | Sabirzyanov.Rinat@tatar.ru |